ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Келәнче авыл җирлеге Советы**
Кама Тамагы районы,
Келәнче авылы
тел. 8-84-(377)- 33-4-31

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Совет Клянчеевского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Клянчеево
тел. 8-84-(377)- 33-4-31

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02.12.2019** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлегенең Келәнче авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2019 елның 13декабрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлегенең Келәнче авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегенең Келәнче авылы торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән,кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме”:
- чүп үләннәрен чабу (җәйге-көзге чорда);

- суүткәргеч һәм су чыганакларын ремонтлау;
- Бәки авылы зиратына якын килү юлларын төзекләндерү;
- авыл эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- тукталыш павильонын ремонтлау;
- вакытлыча каты көнкүреш калдыклары полигоннарын карап тоту һәм чистарту.»

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35,
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур., шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 3(өч) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Келәнче авылы**
**җирлеге башлыгы** **Д.А.Кадыров**